СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

15.06.2020 № 123

## Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советына депутатлар сайлаулары билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Уставының 13 статьясы нигезендә Утар-Атыавыл жирлеге Советы **карар бирде**:

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча “Арча хәбәрләре” (“Арский вестник”) район газетасында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда ТР, Арча районы, Утар-Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт; ТР, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшьләр урамы, 6 йорт; ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай урамы, 1 адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева